СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск № 533

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Кабан-Бастрык авылында гражданнар арасында сораштыру үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советының 2008 елның 24 октябрендәге 237 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнар арасында сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәгә таянып, җирле үзидарә органнары карарларын кабул итү өчен җирлек халкының фикерен ачыклау максатыннан, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Кабан-Бастрык авылы территориясендә сайлау хокукына ия гражданнар арасында сораштыру үткәрүне билгеләргә һәм уздырырга.

2. Гражданнар арасында сораштыруга түбәндәге сорауны чыгарырга: «Түбән Биш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Кабан-Бастрык башлангыч гомумбелем мәктәбе» филиалын ябу белән килешәсезме? ».

3. Билгеләргә:

3.1. Сораштыруда катнашучы Дүрт Мунча авыл җирлегенең Кабан-Бастрык авылында яшәүчеләрнең минималь саны 50 кеше дип .

4.2. Гражданнар арасында сораштыру үткәрүне башлау вакыты - 2020 елның 16 июне, гражданнар арасында сораштыру үткәрү тәмамлану вакыты - 2020 елның 17 июне.

3.3. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү вакыты - 2 календарь көн.

4. Расларга:

4.1. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү комиссиясе составын әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

4.2. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү методикасын әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә.

Гражданнар арасында сораштыру үткәрү буенча комиссиянең беренче утырышын үткәрүне түбәндәге адрес буенча билгеләргә:Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Крупская урамы, 6 нчы йорт.

5. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү буенча комиссиягә:

5.1. Сораштыру үткәрүне оештырырга.

5.2. Әлеге карарга 3нче кушымта нигезендә форма буенча сораштыру кәгазе әзерләүне тәэмин итәргә.

5.3.Сораштыру нәтиҗәләрен Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6.Сораштыруларны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чараларны финанслау Зәй муниципаль районының җирле бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

7. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В.Г. Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Советының
03.06.2020 ел 533 номерлы карарына
1нче кушымта

Гражданнар арасында сораштыру үткәрү буенча комиссия составы

| № п/п | Ф.И.А., вазыйфасы |
|---|---|
| 1. | Вахитова Ирина Александровна, «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ методисты (килешү буенча) |
| 2. | Ситдыйков Радик Такъсин улы, 7нче округ буенча Дүрт Мунча авыл җирлегеннән Зәй муниципаль районы Советы депутаты, Зәй муниципаль районының Дурт Мунча авыл җирлеге башлыгы |
| 3. | Журавлева Юлия Сергеевна, «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ әйдәп баручы белгече (килешү буенча) |
| 4. | Ермаков Юрий Егорович, 6нчы округ буенча Дүрт Мунча авыл җирлегеннән Зәй муниципаль районы Советы депутаты |
| 5. | Хәлиуллин Геннадий Сәмигулла улы, Зәй муниципаль районы ветераннар советы рәисе (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Советының
03.06.2020 ел 533 номерлы карарына
2нче кушымта

Гражданнар арасында сораштыру үткәрү методикасы

1. Сораштыруның максаты: Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Түбән Биш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Кабан-Бастрык башлангыч гомумбелем бирү мәктәбе” филиалын ябу мәсьәләсендә Кабан-бастрык авылында яшәүчеләрнең фикерен ачыклау һәм аны карар кабул иткәндә исәпкә алу.

2. Сораштыру объекты: Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт Мунча авыл җирлеге Кабан-Бастрык авылының сайлау хокукына ия халкы. Сораштыруда катнашучы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең минималь саны 50 кеше дип билгеләнгән.

3. Мәгълүмат җыю методлары: мәгълүмат җыю яшәү урыны, эш (уку) урыны буенча, гражданнар күп була торган бүтән урыннарда сорашып белешү кәгазен тутыру юлы белән үткәрелә.

Гражданнар арасында сораштыру үткәрүгә комиссия муниципаль берәмлекнең башка кешеләрен дә җәлеп итә ала.

Яшәү урыны буенча гражданнар арасында сораштырулар уздырганда сораштыруны алып баручы зат кешене сораштыруга чыгарылган сорау (сораулар) һәм сораштыру кәгазен тутыру тәртибе белән таныштырырга тиеш. Сораштыруда катнашучы шәхесен һәм яшәү урынын таныклаучы документын күрсәткәч, сораштыру кәгазе ала, сораштыру кәгазендә сораштыру датасын, үзенең фамилиясен, исемен, этисенең исемен, яшәү урыны адресын, туган көнен тулысынча күрсәтә, үзенең ихтыяры нигезендә сораштыру кәгазендәге «Сорау» графасында «риза» яки «риза түгел" җавап вариантының берсен сайлап, билге сала, үз имзасын куя, шулай ук икенче имза белән «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын раслый һәм тутырылган сораштыру кәгазен сораштыруны алып баручы затка кире кайтара. Сораштыруны башкаручы зат тутырылган сораштыру кәгазенә имзасын сала, датасын куя, үзенең фамилиясен, исемен, этисенең исемен күрсәтә.

Сораштыру кәгазен тутырганда карандаш кулланырга рөхсәт ителми.

Сораштыруда катнашучыларның яшәү урыны буенча сораштыру үткәрү вакыты дәвамында көн саен сораштыруда катнашучылар исемлеге, тутырылган сораштыру кәгазьләре, сораштыру кәгазьләренең калган чиста бланклары сораштыруны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан комиссия әгъзаларына җибәрелә.

4. Дүрт Мунча авыл җирлегенең Кабан-Бастрык авылы гражданнарыннан сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорау мәгариф учреждениесен ябу мәсьәләсе буенча халык фикеренә кагыла.

5. Сораштырулар нәтиҗәләрен эшкәртү сораштырулар үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауга респондентларның җавап вариантлары санын санау, алга таба бер үк төрле фикерләр булган респондентларның өлешен билгеләү юлы белән үткәрелә.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Советының
03.06.2020 ел 533 номерлы карарына
3нче кушымта

# СОРАШТЫРУ КӘГАЗЕ

| Сораштыру-ның датасы | Сораштыруда катнашучының Ф.И.А. | Сораштыруда катнашучының туу датасы | Сораштыруда катнашучының яшәү адресы | Сорау: “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Түбән Биш урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең “Кабан-Бастрык башлангыч гомумбелем мәктәбе” филиалын ябу белән килешәсезме?” Җавапның варианлары: риза/ риза түгел | Сораштыруда катнашучының имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы таләпләре нигезендә, Зәй мукиципаль районы Сәвәләй авыл жирлеге гражданнары арасында сораштыру процедурасын тәэмин итү максатларында, гражданнар арасында сораштыру үткәргәндә комиссиягә автоматлаштырылган, шулай ук шәхси мәгълүматларны автоматлаштыру чараларын кулланмыйча гына эшкәртергә, аерым алганда, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 3 пунктында каралган гамәлләрне кылуга ризалыгымны бирәм

Эшкәртүгә мин ризалык бирә торган шәхси мәгълүматларга керә: фамилия, исем, әтинең исеме; туу датасы, адрес һәм гамәлдә булу вакытын чикләмичә, гражданнарны сораштыру белән бәйле башка мәгълүматлар керә.

Шәхси мәгълүматларым белән барлык гамәлләрне (операцияләрне) башкаруга хокук бирәм, шул исәптән жыю, системалаштыру, туплау, саклау, куллану, иясезләндерү, блоклау, юк итүне дә кертеп. Оператор минем шәхси мәгълүматларны электрон мәгълүматлар базасына кертү, исемлекләргә (реестрларга) кертү һәм хисап мәгълүматларын (документларны) бирүне регламентлаучы документларда каралган хисап формаларын эшкәртергә һәм аларны вәкаләтле органнарга тапшырырга хокуклы

Әлеге килешү имзаланган көннән алып язмача рәвештә кире алынган көнгә кадәр гамәлдә. Минем язмача гаризам нигезендә ризалыгымны кире алу хокукы булу турында белүемне раслыйм.

“Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны раслыйм __________ ___________________________ /______________________________/

(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Сораштыру үткәрүче затның имзасы __________ ___________________________ /______________________________/